ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

15.08.2022 п.г.т.Алексеевское № 317

**«Җирле әһәмияттәге автомобиль юллары озынлыгының норматив таләпләргә туры килә торган өлеше»күрсәткечен хисап чорына (узган ел) җыю һәм мониторинглау механизмы буенча Татарстан Республикасы Алексеевск җирле үзидарә органы эшчәнлеге регламентын раслау турында**

Россия Федерациясе Президентының «2030 елга кадәрге чорга Россия Федерациясен үстерүнең милли максатлары турында» 2020 елның 21 июлендәге 474 номерлы, «Россия Федерациясе субъектларының югары вазыйфаи затлары (дәүләт хакимиятенең югары башкарма органнары җитәкчеләре) эшчәнлегенең һәм Россия Федерациясе субъектлары башкарма хакимияте органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү турында»2021 елның 4 февралендәге 68 номерлы указлары нигезендә

**карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы җирле үзидарә органының хисап чорында (узган ел) «Норматив таләпләргә туры килә торган җирле әһәмияттәге автомобиль юллары озынлыгының өлеше» күрсәткечен җыю һәм мониторинглау механизмы буенча эшчәнлек регламентын расларга (Кушымта).
2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга http://alekseevskiy.tatarstan.ru .
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасары М.Р. Гайсинга йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **О. А. Гайнуллин**

Алексеевск муниципаль
районы Башкарма
комитетының
2022 ел 15 августыннан,
№317 карарына кушымта

**Алексеевск муниципаль районы җирле үзидарә органының хисап чорында (узган ел) «Норматив таләпләргә туры килә торган җирле әһәмияттәге автомобиль юллары озынлыгының өлеше» күрсәткечен җыю һәм мониторинглау механизмы буенча эшчәнлек Регламенты**

## I. Гомуми нигезләмәләр

Әлеге Регламент (Алга таба – Регламент) хисап чорына(үткән елга) «Норматив таләпләргә туры килә торган җирле әһәмияттәге автомобиль юллары озынлыгының өлеше» күрсәткечен мониторинглау өчен эшләнгән.

Алексеевск муниципаль районында күрсәткеч күрсәткечләрен җыю һәм мониторинглау өчен җаваплылык үзәге булып Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге (алга таба - Башкарма комитет) тора.

Күрсәткечләр турында мәгълүмат белән тәэмин итүчеләр булып Алексеевск муниципаль районының шәһәр һәм авыл җирлекләре Башлыклары тора.

Күрсәткеч билгеләре турында мәгълүмат бирү формасы Регламентка кушымтага туры килергә тиеш. Муниципаль район буенча агрегацияләнгән мәгълүмат аңа кергән җирлекләр мәгълүматлары нигезендә төзелә һәм регламент режимында«Идарә нәтиҗәлелеген бәяләү»мәгълүмати-аналитик системасында,Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан, «Норматив таләпләргә җавап бирми торган җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юллары озынлыгының җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларының гомуми озынлыгында өлеше, процент", алар эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү өчен шәһәр округлары һәм муниципаль районнар башлыклары докладларын әзерләү кысаларында,фараз күрсәткечләрен килештерү өчен тутырыла. Бер үк вакытта алынган һәм тапшырыла торган мәгълүмат Алексеевск муниципаль районында Башкарма комитет җитәкчесе боерыгы белән билгеләнгән мәгълүмат җыю һәм мониторинглауны тәэмин итүче җаваплылык үзәге тарафыннан архивлана.

## II. Төшенчә аппараты

Әлеге модель актта кулланыла торган терминнар һәм билгеләмәләр «Россия Федерациясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2007 елның 8 ноябрендәге 257-ФЗ номерлы Федераль законда китерелгән.

3-ДГ (МБ) формасы-федераль дәүләт статистикасы хезмәтенең 2021 елның 30 июлендәге 458 номерлы боерыгы белән расланган «Җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юллары һәм аларга ясалма корылмалар турында мәгълүматлар» федераль статистик күзәтү формасы.

## III. Мәгълүмат җыю тәртибе, сроклары һәм формалары

Күрсәткечне исәплəү өчен түбәндәге мәгълүматлар кулланыла:

транспорт-эксплуатация күрсәткечләре буенча,норматив таләпләргә туры килә торган муниципаль районда җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларының гомуми озынлыгы-хисап елының декабрь ахырына, км;

муниципаль районда җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларының гомуми озынлыгы-хисап елының декабрь ахырына, км.

Башкарма комитет җирле әһәмияттәге юллар турында мәгълүматларны Алексеевск муниципаль районының шәһәр һәм авыл җирлекләре башлыкларына рәсми запрослар җибәрү юлы белән 3-ДГ(МБ) формасы буенча мәгълүматларны тапшыру датасына кадәр бер айдан да соңга калмыйча, Дәүләт статистикасы федераль хезмәтенең (алга таба - Росстат) территориаль органына (алга таба-Росстат) җибәрә.

Алексеевск муниципаль районының шәһәр һәм авыл җирлекләре Башлыклары тарафыннан мәгълүмат электрон рәвештә электрон документ әйләнеше системасында яки электрон почта адресы буенча Башкарма комитетның җаваплылык үзәгенә тапшырыла.

Җаваплылык үзәгенең вазыйфаи заты Регламентка кушымта нигезендә электрон рәвештә кергән мәгълүматны исәпкә алып бара. Әлеге мәгълүматларны җыю һәм эшкәртү нәтиҗәләре буенча җаваплылык үзәгенең вазыйфаи заты ел саен, хисап елыннан соң килүче 25 апрельдән дә соңга калмыйча, «Идарә нәтиҗәлелеген бәяләү»мәгълүмати-аналитик системасында ирешелгән күрсәткечнең әһәмияте турында мәгълүматларны тутыра.

Җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге шәһәр һәм авыл җирлекләре торак пунктлары чикләрендә махсус оешмалар белән төзелгән контрактлар (шартнамәләр) нигезендә, Россия Федерациясенең гамәлдәге законнары, шулай ук муниципаль заказны урнаштыру өлкәсендә мөнәсәбәтләрне җайга салучы Алексеевск муниципаль районы җирле үзидарә органнарының норматив хокукый актлары нигезендә гамәлгә ашырыла.

Авыл җирлегенең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге үз эченә ала:

- автомобиль юлларының техник торышын бәяләү;
- автомобиль юлларын карап тоту һәм ремонтлау;
- автомобиль юлларын карап тоту һәм ремонтлау буенча эшләр башкару;
- автомобиль юлларын карап тоту һәм ремонтлау эшләрен кабул итү.

**Башкарма комитетның**
**Эшләр идарәчесе** **Г.Ә.Йосыпова**

Регламентка кушымта

1. Күрсәткечләр мониторингы формасы

| т/б № | Муниципаль районның жирлегенең, шәһәр округының исеме | Норматив таләпләргә туры килә торган жирле әһәмияттәге автомобиль юллары озынлыгының өлеше | | |
|---|---|---|---|---|
| | | % | Юлларның гомуми озынлыгы, км | Норматив халәттәге юлларның озынлыгы , км |
| 1 | | | | |
| 2 | | | | |